# Халыклар бердәмлеге көне белән!

# Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 30 октябрь 2015 ел №80 (10609)


**31 октябрьгә һава торышы:** болытлы һава, урыны белән кар, җил төньяктан, 5-6 м/с; температура көндез 0°С, төнлә -1°С

КОТЛАУ

**Хөрмәтле нурлатлылар!**

Сезне чын күңелдән Халыклар бердәмлеге көне белән котлыйм!

Халыклар бердәмлеге көне чагыштырмача яшь бәйрәм булса да, аның тирән тарихи тамырлары бар. Татарстан бүген социаль-икътисади тотрыклылыкка, конфессияара татулыкка һәм милли-мәдәни традицияләрне ныгытуга йөз тоткан вәзгыяте белән дөньякүләм танылу алды. Бу вәзгыять Нурлат районы сәясәтенең дә нигезендә ята. Төп өч милләт – татар, рус, чуваш халкының кулга-кул тотынышып эшләве, тату яшәве безгә район алдында торган иң катлаулы үсеш программаларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Быел ачылган Халыклар Дуслыгы йорты – нәә шушы татулыкка, бердәмлеккә өндәп торучы уртак йортыбыз ул. Безнең һәрберебез үзенең киләчәген республика, үзе яши һәм эшли торган төбәк язмышы белән бәйли һәм аның тотрыклы үсешен кайгырта. Ватаныбызның лаеклы иртәгәсе, киләчәк буыннарның иминлеге, татулыгы хакына хезмәттә безнең нурлатлылар да зур өлеш кертәсенә шикләнмим. Һәрберебезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, яңа бәхет-шатлыклар телим.

**Равил Кузюров,**
**Нурлат районы һәм шәһәре башлыгы.**

**Концертка рәхим итегез!**

4 ноябрь көнне 18.00 сәгатьтә Халыклар Дуслыгы йортында Халыклар бердәмлеге көненә багышлап " Туган җир аһәңнәре" дигән зур концерт була. Бәйрәм концертына рәхим итегез!

**Укучыларыбыз игътибарына!**

Чәршәмбе, 4 ноябрь – ял көне булу сәбәпле, газетабызның чираттагы саны пәнҗешәмбе, 5 ноябрьдә чыгачак.

**РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ӘБУНӘ ДӘВАМ ИТӘ.**
*БЕЗ СЕЗНЕ ПОЧТАДА ҺӘМ РЕДАКЦИЯДӘ КӨТӘБЕЗ.*

## Вакыт үзе таләп куйды



Автор фотосы

Олег Казаков, Евгений Шерников, Гөлсем Билданова һәм Рәйсә Максимова көнбагыш киптерүдә мәшгуль

**Басу-кырларда бөртеклеләрне урыпҗыю күптән тәмамланды. Әмма "Нурлат элеваторы" җәмгыятендә эшләр дәвам итә. Быел бирегә беренче тапкыр көнбагыш кабул итәләр.**

Бу техник культурага районда игътибар елдан-ел арта бара. Әнә, узган елда кояш чәчәгенең мәйданнары 3000ләп гектар тәшкил иткән булса, быел ул 7000ләп гектарда игелде. Ә мәйданнар арту, әлбәттә инде, аны саклау, киптерү ихтыяҗын да тудырды һәм "Нурлат элеваторы"нда быелдан бу эшне башлап җибәрделәр. Бу исә быел элеваторда яңа "Веста" бөртек киптергече кәйләү белән мөмкин булды. Сәгатенә 50 тоннага якын бөртек киптерергә мөмкинлек бирүче бу заманча җайланманы көнбагыш өчен дә файдаланалар бирегә.

Элеватор хезмәткәрләре өчен көнбагыш – яңа культура. Әмма, аны кабул итү, киптерүнең барлык нечкәлекләренә өйрәнергә өлгергәннәр. Әнә, лабораториядә элеваторга килгән һәр йөктән тикшерү өчен үрнәкләр алалар һәм әле бер айлап элек кенә кайтарылган яңа гидравлик пресс һәм һава суыру шкафы, реагентлар ярдәмендә майлылыкны билгелиләр.

– Яңа җиһазлар безгә төгәл анализлар ясарга, майлылыкны билгеләргә мөмкинлек бирә. Ул 4 процентка кадәр булырга тиеш, - ди җитештерү лабораториясе начальнигы Лилия Албаева.

Лаборатор тикшерү аша узган көнбагыш складка, аннан киптергечкә китә. Киптергечнең көйле һәм тотрыклы эшләвен аппаратчы Олег Казаков идарә пульты аша күзәтеп тора.

– Бик җайлы. Яңа киптергечнең егәрлеге дә, мөмкинлекләре дә зур. Барлык эш тә автоматлаштырылган. Пультта барлык параметрлар да чагылыш таба, шуннан карап, көйлисе генә кала, - ди ул.

Киптергеч аша чыккан көнбагышны исә Казанның май-экстракцион заводына эшкәртүгә алып китәләр. Аны урдыра башлаганнан бирле элеватор аша 1000 тонналап көнбагыш заводка озатылган икән инде.

Ә элеваторда бу юнәлештә эшләрне алга таба да дәвам иттермәкчеләр, киләсе елга җылылык алмаштыргычлар сатып алырга ниятлиләр.

– Бу безгә җитештерүчәнлекне арттырырга, элеваторның эшен тагы да заманчарак итәргә мөмкинлек бирәчәк. Яңалыклар һәм үзгәрешләр кертү – вакыт таләбе, - ди элеваторның генераль директоры Мансур Гайфуллин.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

МӘКТӘПЛӘРДӘ

## Каникул ял вәгъдә итә

**2 ноябрьдән район мәктәпләре укучыларының көзге каникуллары башлана. Каникул 8 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк.**

- 2015-2016 уку елына балаларның гомере һәм сәламәтлегенең куркынычсызлыгын тәэмин итәрлек оешкан ял булдыруга шартлар тудыру, укучылар өчен үткәрелә торган чараларның бердәм планын гамәлгә ашыру максатыннан һәм эти – әниләрнең купсанлы сораулары буенча, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы көзге каникулларның бердәм вакытын тәкъдим итте, - диде район мәгариф бүлеге җитәкчесе урынбасары Эльмира Шагаева. Район башкарма комитетының мәгариф бүлегендә хәбәр итүләренчә, каникуллар чорында 18 белем бирү учреждениесендә мәктәп яны лагерьлары эшләячәк. Моннан тыш, һәр мәктәпнең каникул чорына үз планы булдырылган. Бу чорда мәктәпләрдә БДИ, ОГЭга әзерлек эшләре дәвам итәчәк, экологик темага багышланган викторина, спорт линиясе буенча волейбол, футбол һәм баскетбол ярышлары, башлангыч сыйныфларда юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнү буенча дәресләр узачак. Каникуллар чорында да мәктәпләрдә көзге баллар дәвам итәчәк, музейларга һәм шәһәрләргә экскурсияләр планлаштырыла. Атна дәвамында һәр мәктәпнең ишеге балалар өчен ачык булачак, дип хәбәр итәләр.

Каникулларны укучылар гына түгел, аларның эти – әниләре дә көтеп ала икән.

- Мәктәпләрдә каникулларны бер үк вакытта булдыру балалар өчен дә, без - өлкәннәр өчен дә кулай, - ди нурлатлы Ольга Назарова. – Бу атнада өлкәннәр өчен дә ике көн бәйрәм ялы каралган. Балалар белән бергә булачакбыз.

**Зилия ӘКСАНОВА**



Автор фотосы

2нче мәктәпнең 10Б сыйныфы укучылары каникулларга шат

КӨН АРТЫННАН КӨН

# Мәйданчыклар балалар өчен төзелә




МӘЙДАНЧЫКЛАР КОЯШЛЫ КӨННӘРНЕ ҺӘМ БАЛАЛАРНЫ КӨТӘ

Быел көз чын табигать бүләге булды. Җәйге һаваны хәтерләткән җылы көннәр бакчачылар өчен дә, төзелеш эшләре алып баручылар өчен дә бик уңайлы килде. Бигрәк тә бала-чага сөендә матур һава торышына. Ишегалларындагы уен мәйданчыклары аларның шат тавышларыннан тынып тормады. Яңа мәйданчык урнаштырылган Тимерҗанов урамындагы мәйданчыкта исә якын-тирә урамнардан җыелган балалар караңгы иңә башлагач кына таралыша торган булдылар.

– Бигрәк рәхәт бит балаларга, – диде нәни сабыйларын алып килгән Лилия Әндарова.

– Кызлар килергә ашкынып кына тора. Шөкер, Нурлат күзгә күренеп яңара, уңайлыклар арта. Уен мәйданчыклары да шактый.

Әйе, быел гына да шәһәрдәге күпкатлы йортлар ишегалларына 8 балалар уен мәйданчыгы куелды. Шушы көннәрдә генә подрядчы – "Интеллектуаль технологияләр" фирмасы аның соңгысын файдалануга тапшырды.

– Мәйданчыклар халык белән очрашулар барышында шәһәрләрдән кергән үтенечләр адреслары буенча куелды, – ди шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин. – Шуңа ул шәһәрнең төрле микрорайоннарында урнаштырылды.

Һәм бу шулай да. Әнә, аларның бер өлеше шәһәр үзәгенең Сәлимҗанов ур. 7,9; Тынычлык ур., 11; Гыйматдинов ур., 82а; Карл Маркс ур,1 йортларын бизәсә, икенчесе Дружба ур., 70, өченчеләре шикәрчеләр бистәсенең Завод ур., 24,26,28; Ленин ур.,28; Садовая ур.,2а йортлары балаларын сөендерәчәк. 1 млн. сумга якын бәягә төшкән әлеге 8 мәйданчыкны төзү шәһәр бюджеты хисабына башкарылган.

Шәһәрдә күпкатлы йортлар территориясен тәртипләү, заманча рәвешкә китерү буенча соңгы ике елда алып барыла торган масштаблы эшчәнлекнең бер юнәлеше ул балалар мәйданчыклары төзү. Капиталь ремонт үткәрелгән, йорт яны территориясе асфальтланган, ишегалларында бастырылган мәйданчыклар бирердә төзекләндерү буенча тулы эш циклы башкарылуын күрсәтә. Шәһәрдә шулай комплекслы төзекләндерү алган йортлар саны арта бара. Узган елда да ишегалларында шәһәр бюджетыннан 850 мең сумга 7 шундый типовой мәйданчык урнаштырылган булган. Моннан тыш, узган ел "Нурлатнефть" НГДУсы Дружба ур., 78 – 74 йортлары ишегалдында балалар өчен бик зур мөмкинлекләр тудырылган тулы уен шәһәрчеге төзегән иде, гомумән, соңгы 2 елда НГДУ гына да шәһәргә 4 мәйданчык бүләк иткән. "ТатРИТЭКнефть" ТППсының Җинүнең 50 еллыгы микрорайонында җиһазлаган уен мәйданчыгы да бик тиз арада балаларның яраткан урынына әверелде. Шулай итеп, игънәчеләр шәһәр проблемасын хәл итүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Район җитәкчелеге белән очрашулар вакытында уңайлыклы йортларда яшәүчеләр үз балаларына булдырылган мондый мөмкинлектән бик канәгать булып рәхмәт әйткән иделәр инде. Быел тормышка ашырылган үтенечләргә сөенеп безгә рәхмәт хатлары китерүчеләр дә булды. Әле бит быел да шәһәр средстволарына төзелгәннәрдән тыш, "РИТЭК" социаль проектлар конкурсы Грантларына төзелгән янә ике мәйданчык өстәлде. Пионерская ур., 1, Нефтьчеләр ур., 24 йортлар ишек алларына куелган уен җайланмалары 100әр мең сумлык иде. Ә Тимерҗанов урамында "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы, ТР Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салихов инициативасы буенча төзелгән балалар мәйданчыгы янында ук заманча спорт мәйданчыгы кушылган комплекс иң зур шәһәрләр йөзен дә бизәрлек булып чыкты, һәм аннан балалар бер дә өзелми.

Әнә шулай, шәһәр балаларына уен, спорт белән шөгыльләнер, саф һавада күмәк чаралар оештырыр өчен уңайлыклар арта бара. Монда, әлбәттә, ясалма өслекле спорт мәйданчыклары да үз уңай рольләрен уйныйлар. Быел шәһәрдә аларның саны янә 2гә артты.

– Балалар мәйданчыкларын төзү эшен киләчәктә дә дәвам итәргә тырышачакбыз, – ди шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин. – Шул ук вакытта шәһәрлеләрдән булган мәйданчык җиһазларын сак файдалануларын сорар идек. Бу эштә идарәче компанияләр, торак милекчеләре дә контрольне киметмәсләр, дип ышанабыз. Яңа уен җиһазлары барлык таләпләрне күздә тотып эшләнгән, алар арзан түгел, шуңа да алар усал ниятләр өчен җимерү-коч күрсәтү объектларына әверелмәсеннәр, үз багланышларында балаларга хезмәт итсеннәр иде.

Вакытлы искәртү. Һәм урынлы да. Димәк, иҗтимагый контроль да артык булмаячак, ә алары инде – сез һәм без.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

КАЛЕНДАРЬДА ДАТА

## БУРЫЧ БӘЯСЕН БЕЛӘЛӘР

**1 ноябрь–Суд приставлары көне. Суд приставлары федераль службасының ТР буенча идарәсенең Нурлат бүлеге барлык күрсәткечләр буенча республикада 7нче урында бара.**

Ә күрсәткечләр бик тә саллы саннардан тора: быелның 10 аенда 15 кешелек коллектив тарафыннан 8 меңнән артык башкарма эш үтәлгән, 68 млн. 339 мең сум бурыч түләтелгән. Соңгылары күбрәк торак-коммуналь хезмәтләргә кагыладыр, дисәк, ялгышканбыз.

– ТКХ-хезмәтләр өчен бурычлар бездә 2 процентлап кына тәшкил итә, – ди бүлек начальнигы Александр Катков. – Безгә вак штрафлардан алып иң эре кредитларга кадәр бурычны кайтару белән эш итәргә туры килә.

Эш нагрузкасы зур булса да, әзерлекле коллектив куелган бурычларны әйбәт кенә үтәп килә икән. Чөнки үзләре бурычлар кайтару белән эш итүче коллектив өчен хезмәт бурычларын үтәү – икеләтә намус эше. Ә 5 ноябрьдә өч служба ветераны һәм өч хезмәткәрдән торган Нурлат делегациясе Казанга, "Корстон" кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексында федераль службаның 150 еллыгы уңаеннан үткәрелә торган бәйрәм тантанасына барырга җыена.

**Сәкинә НУРУЛЛИНА**

## ЫШАНЫЧЛЫ САК АСТЫНДА

**Кичә ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен штат режимында, эштә билгеләп үттеләр. Әлеге служба оешуга быел 63 ел тулды.**

– Безнең җаваплылык зонасында 512 объект, 56 фатир, 157 коттедж, гаражлар һәм нурлатлылар белән аксубайлыларның милекләре саклана торган башка урыннар бар, – ди Нурлат районы ведомстводан тыш сак бүлеге җитәкчесе Илсур Шәйдуллин. – Әлеге объектларны җинаятьчеләрдән саклау белән бергә, ведомстводан тыш сак бүлеге аларның һәм шәхси секторның терроргa каршы торучанлыгын көчәйтү бурычларын да үти. Көн саен безнең служба иң җинаятьчел микрорайоннарны әйләнеп чыга, җәмәгать тәртибен саклый.

Нурлат районы ведомстводан тыш сак бүлегендә штатта 27 хезмәткәр исәпләнә һәм 21 кеше – ирекле ялланып эшләүчеләр. Алар сак сигнализациясе чараларыннан кергән хәбәрләр буенча тиз эш итәләр, һәм үзләренә караган объектларның ышанычлы сак астында булуын эштә күп тапкырлар исбатладылар инде.

**Маргарита ЛИТТА**

ИГЕЛЕК

# Шатлык бүләк иттеләр

**Яшьләр шаярып һәм ял итеп йөрергә генә түгел, файда да китерергә тиеш.**

"Нурлатнефть" НГДУсының яшьләр комитеты чираттагы киңәшмәләрнең берсендә шундый нәтиҗәгә килде. "Игелек кылырга ашык" акциясе үткәрү идеясе шулай туды.



НУРЛАТ НЕФТЬЧЕЛӘРЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЧЫН БӘЙРӘМ ОЕШТЫРДЫ

Активистлар башта Аксубай социаль ятимнәр йортындагы игътибар һәм кайгыртуга аеруча мохтаҗ булган балаларга булышуларын сорап төсле игъланнар ябыштырдылар. Һәм предприятиедә игелекле йөрәкле кешеләр шактый булып чыкты.

Ай дәвамында битараф булмаган хезмәткәрләр уенчыклар, китаплар алып килделәр, акчалата ярдәм җыйдылар. Җыелган средстволарга кышкы җылы башлыклар, бияләйләр, оекбашлар, уенчыклар һәм тәм-томнар сатып алынды. Әмма акцияне оештыручыларга бу гына аз тоелды. Егет-кызлар бүләкләрне илткәндә шоу-программалы бәйрәм оештырырга карар кылдылар. Өстәвенә, уенчыклар һәм тәм-томнар шулкадәр күп җыелды ки, берочтан балалар бакчаларына да кереп чыгарга дип хәл иттеләр. Башта бүләкләрне Нурлат районының Егоркино һәм Мамык балалар бакчаларына йөрүчеләр алды. Ә Аксубай ятимнәр йортындагы балаларның әкият геройларының килүенә ничек сөенүләрен күрсәгез! Аларның кәефләрен шат күңелле клоуннар һәм Витаминка күтәрде. Ә робот Робинның тылсымлы механизмын кабызу өчен балаларга күп чабарга, тыпырдарга, хәтта сызгырырга һәм биергә дә туры килде.

Мавыктыргыч уеннардан соң һәр бала көтелгән бүләген алды. Очрашу бик күңелле һәм өйдәге сыман узды, соңыннан берәүнең дә хушлашасы килмәде. Аерылышканда исә акциядә катнашучылар бирегә янә килергә вәгъдә бирделәр.

**Марина КОРНИЛОВА,**
"Нурлатнефть" НГДУсының яшьләр лидеры.

# МАНЗАРА

ЯГУ СЕЗОНЫ

## Янгын җавапсызлыкны кичерми

**2014-2015 елгы ягу сезоны дәвамында районда 3 млн. сумнан артык матди зыян китергән 40 янгын очрагы булган.**

– Ягу чорында чыккан янгыннарның төп сәбәпләре – мич һәм төтен юлларының төзелеш һәм кулланылыш, электр җиһазларын монтажлау һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен бозу, аек булмаган затлар гаебе белән уттан саксыз файдалану, – диде районара бүлекнең күзәтчелек эшчәнлеге буенча баш белгече Әлмарис Талипов. – Янгын вакытында 2 кеше һәлак булды, шуның кадәрлесенә зыян килде, төзелеш корылмаларының 20се тулысынча янып бетте, 18е – зарарланды, 2 автотрактор техникасы юкка чыкты.

Февральдә вторметның көнкүреш вагоны янып бетте. Янгын мичтән кулланганда янгын куркынычсызлыгын бозу нәтиҗәсендә килеп чыккан. Йоклап киткән каравылчы төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган. Электр җиһазларын файдаланганда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәмәү нәтиҗәсендә бер шәхси эшмәкәрнең махсуслаштырылган кибетендә шактый зур зыян китергән янгын чыккан.

Әлмарис Талипов әйтүенчә, узган ягулык чорында килеп чыккан янгыннарның иң күбе – 35 очрак – шәхси секторга карый. Бу уңайдан Әхмәт, Егоркино, Мамык, Иске Чаллы кебек авыл җирлекләрен, шулай ук шәһәрнең үзен дә билгеләп үтәргә мөмкин.

– Җирле үзидарә органнары халык арасында янгынга каршы пропаганданы һәм янгын куркынычсызлыгы чараларын өйрәтүне начар оештыралар һәм алып баралар, – ди Әлмарис Талипов. – Торак пунктлар янгынга каршы "01 хезмәте кисәтә" дигән стендлар белән җиһазландырылмаган, ирекле янгын формированиеләренең уңышлы эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар булдырылмаган.

Чираттагы ягу периоды башланды. Кышның нинди буласын берәү дә белми. Әмма, өйдә җылы булсын өчен, мич һәм җиһазларның төзеклеген алдан ук карап куярга кирәк. Янгын җавапсызлыкны кичерми.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

**САН**

**40 янгын очрагының 28ендә, янгын сүндерү подразделенияләре килгәнче, ут белән авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ирекле янгын формированиеләре көрәшкән.**

КЫСКАЧА

### СРОГЫ ЧЫККАН АШАМЛЫКЛАР...

2015 елның 9 ае эчендә Нурлат районында яраклылык вакыты чыккан ашамлыклар сатуның 10 очрагы билгеле булган. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, 23,3 мең сумлык сыйфатсыз азык-төлек товары сатудан алынган.

– Гамәлдәге закон буенча, тикшерүче органнарның мөмкинлекләре чикләнгән, кулланучылар хокукларын бозу турында язма рәвештә кабул ителгән шикаятьләр генә планнан тыш тикшерүләргә сәбәп була ала, – ди Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чистай территориаль органы белгече Алия Гатина. – Кибетләрдә сыйфатсыз азык-төлек товарлары сату фактлары белән очрашкан кешеләр безгә мөрәҗәгать итеп, гариза язып калдыра алалар. Ул планнан тыш тикшерүләр оештыру өчен нигезләмә булачак.

### ҺӘМ ЯЛГАН АРАКЫ САТУ БУЕНЧА ФАКТЛАР АЧЫКЛАНДЫ

**9 ай эчендә Нурлат районында өйдә җитештерелгән һәм этил спирты катнашкан эчемлек сатуның 27 очрагы теркәлгән.**

– Сентябрьдә башкарма комитет, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе, Россиянең Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча вәкилләре катнашындагы мобиль төркем шәһәр кафеларының берсендә Казахстанда җитештерелгән исерткеч эчемлекләр саклануын ачыклады. Районда барлыгы 770 литр легаль булмаган исерткеч эчемлекләр сатудан алынды, – дип хәбәр итте ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең өйдән баручы белгече Алия Гатина.

**Легаль булмаган продукциянең сатылуы һәм башка алкоголь законнарын бозу хакында ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чистай территориаль органы "кайнар линия"сенә (8-84342) 5-10-19, сыйфатсыз азык-төлек буенча Нурлатта – 2-19-45, 2-06-69 телефоннарына хәбәр итәргә мөмкин.**

Сирень СӘМӘРХАНОВА

**Газетаның электрон версиясен nurlat-tat.ru сайтында укыгыз**

БЕЗНЕҢ КОНКУРС

## Балалар елмаю бүләк итә

"Сөйкемле елмаю" конкурсына чираттагы фоторәсемнәрне нурлатлы Рәйсә апа Хәсәнова юллаган.



Ике онытым Алсу белән Айгөлнең зур әниләре мин. Олы онытым мәктәптә белем ала, төпчеге – Айгөл балалар бакчасына йөри. Алсу мәктәптә дә яхшы билгеләренә укый, буш вакытында шигырьләр дә яза. Аның иҗат җимешләрен газета укучыларга да тәкъдим итәргә булдым.



Әтием дә бар минем,
Әнием дә бар минем.
Әби – бабайларым да бар,
Бик бәхетле мин үзем.

**Түбәндәге шигырь юллары Айгөл кызыма:**

Битемдәге миңкәемнең
Каян килгәнен белмим.
Миңле кеше – бәхетле ул,
Була диде, әнием.



4 яшьлек Арслан Гәрәев та үзен конкурста сынап карарга булган. "Чишмәкәй" балалар бакчасына йөрүче нәни малайның хыялы – корабль капитаны булу икән. Шаян малай хоккей белән мавыга, җырларга ярата, әбисе Вәсилә артыннан дини догаларны да яттан өйрәнә, ди.

## Миләш тә, балан да шифа

**Район һәм шәһәр мәктәпләре шул көннәрдә көзге табигать нигъмәтләре – балан, миләш җыю, киптерү белән мәшгуль иделәр. Әлеге эшләр быелның мартыннан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы нигезендә республика мәктәпләрендә башланган дару-техник чимал җыюның соңгы этабы булды.**

Нурлат районында дару үләннәрен, урман җимешләрен җыю 28 урта мәктәп тарафыннан башкарылды.

– Апрельдә каен һәм нарат бөреләре, яз-җәй айларында дару үләннәре, чәчәкләр, яфраклар әзерләп тапшырган идек, көз көне шомырт, балан, кара һәм кызыл миләш җыю һәм киптерү белән шөгыльләндек, – дип сөйли Урта Камышлы мәктәбе директоры Марина Герасимова. – Табигать җимешләрен җыю мәктәп коллективы, укучылар һәм ата-аналарның күмәк тырышлыгы белән башкарылды. 8 ай дәвамында дару үләннәрен әзерләү Татпотребсоюзның "Дару үләннәре. Җыю һәм киптерү кагыйдәләре" дип аталган брошюрасы таләпләрендә алып барылды. Укучылар дару үләннәрен аерырга өйрәнделәр, аларның файдалы үзлекләрен дә үзләштерделәр.

Район мәгариф бүлеге методисты Любовь Ефимова әйтүенчә, дару-техник чимал әзерләү эше октябрь азагында тәмамланган. Һәр мәктәп үзләренә бирелгән план буенча көзге җимешләр – балан, дуләнә, кара һәм кызыл миләш, гөлҗимеш, алма киптерел, шәһәрнең беренче мәктәбендә урнашкан кабул итү пунктына тапшырган. Шәһәр мәктәпләре арасында 1, 4, 8нче, авылларда Урта Камышлы, Киекле, Яңа Иглай мәктәпләре зур тырышлык күрсәткән. Мисал өчен, 8нче мәктәп 70 кг, 4нче мәктәп 52 кг, Яңа Иглай мәктәбе 37 кг кызыл миләш әзерләгәннәр. Шул көннәрдә әлеге продукция Казанның дару-техник чимал кабул итү һәм эшкәртү базасы – "Татарстан дару үләннәре" ОООсына илтеп тапшырылачак. Монда мәктәпләр тарафыннан әзерләнгән чимал тышкы билгеләре буенча билгеле таләпләргә һәм стандартларга туры килү ягыннан сайлап алыначак. Артык киптерелгән, черегән яисә дымлы җимешләр кабул ителми. Шуңа җимешләрне җыю гына түгел, аларны дөрес киптерү дә зур җаваплылык сорый, илтифатсызлык күпме файдалы нигъмәтләрне юкка чыгарырга мөмкин бит.

- Мәктәпләрдә әлеге эшчәнлек биология укытучылары җитәкчелегендә алып барыла һәм мәктәп тормышының аерым бер сәхифәсен били, - ди Любовь Ефимова. – Ул мәктәп коллективының да, балаларның да коры энтузиазмына гына корылган, дип тә әйтергә була. Әлбәттә, тапшырыла торган һәр чималның үз бәясе бар, әмма ул бик символик һәм нинди дер керем, табыш хакында сөйләргә мөмкинлек бирми. Иң мөһиме, ул тәрбияви бурычларның берсен үти - балаларда табигатькә карата сакчыл мөнәсәбәт булдырырга, аларны күмәк файдалы хезмәткә тартырга ярдәм итә.

Татарстан мәктәпләрендә быел башланган дару-техник чимал җыю эшчәнлеге киләсе елларда да дәвам ителер дип көтелә. Шулай булгач, ул бер яктан, экологик чиста дару үләннәре базасын баетса, икенче яктан, укучыларның табигать белән бәйләнешен ныгытып, мәгълүмати потенциалларын арттырырга да булышыр.

Гүзәл САДЫЙКОВА

БУ КЫЗЫКЛЫ



## Могҗизалы тузганак

**Әлеге гигант тузганакны Настя Рукавишникова сентябрьнең соңгы көннәрендә өзеп алган. Ул мәнә бер ай инде чәчәк вазасында быелгы озакка сузылган "әбиләр чуагын" искә төшереп тора.**

Мәктәптән кайтканда Настя үлән арасында йомшак шарчык күреп ала. Сибәләп торучы яңгыр өенә ашыктырса да, кызыксынучанлыгы җиңә аны. Кыз, "чәчләре" җилдә мәнә-мәнә очып китәргә торган тузганакны кызганып, өзеп ала да, кулы белән каплап, өенә алып кайта. Ә икенче көнне беренче кар төшә.

Өйдә гадәти булмаган табылдыкны зур соклану белән кабул итәләр һәм шунда ук үлчи дә башлыйлар – диаметры 12 сантиметр булып чыга аның. Чәчәкнең сабагы каты булганга, ул үзенең формасын саклап калган. Настя тузганак турында дусларына, сыйныфташларына, күршеләренә сөйләгән, хәзер исә йомшак могҗиза белән газетабыз укучыларын да таныштырырга булган. Ул әлеге чәчәкнең һәрберебезгә яхшы кәеф бүләк итәсенә ышана.

Маргарита ЛИТТА

